Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№5 (98)

27 февраль 2014 ел




Фотода: КФУның Яр Чаллы филиалы студентлары башка волонтерлар белән. Студпроф.ру фотосы.



# Эссе. Кышкы. Синеке.

Якшәмбе Сочида XXII кышкы Олимпия уеннары тәмамланды. Русия үз тарихында (Совет чорын да кертеп) иң зур уңышка иреште – ил спортчылары 13 алтын, 11 көмеш, 9 бронза – барлыгы 33 медаль яулады. Олимпия уеннарын уңышлы итеп узыдырып җибәрүдә волонтерлар зур эш башкарды. Татарстаннан киткән 342 волонтерның 46сы КФУ студенты булды. XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада вакытында тупланган тәҗрибәне алар бик урынлы файдалана алгандыр дип уйлыйбыз.

## Вакыйгалар әзеннән

**24 ФЕВРАЛЬ** көнне **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Чара ректор **И.ГАФУРОВНЫҢ** Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры **А.КИЯСОВНЫ** туган көне белән тәбрикләвеннән башланып китте. Башта контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм атна дәвамында үткәреләчәк чаралар хакында административ эшчәнлек буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** җиткерде. Алга таба икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** КФУның конкурентлылыгын арттыру программасын гамәлгә ашыру мәсьәләләре турында сөйләде. Ул шулай ук 2010-2013 елларда Үсеш программасы кысаларында сатып алынган җиһазларның иминлеген һәм кулланылышта булу фактын өлешчә тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырды. Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты директоры **И.ГАЛИЕВ** «Яльчик» укыту-сәламәтләндерү үзәген реконструкцияләү һәм аның эшчәнлеге хакында мәгълүмат бирде. 2014 елда Россия фәнни фондының фәнни грантларына дәгъва кылу өчен, институт һәм факультетлардан гаризалар керү мәсьәләләре турында сөйләде. Тышкы элемтәләр буенча проректор **Л.ЛАТЫЙПОВ** КФУ делегациясенең Хэнань Кытай провинциясенә булган визиты хакында чыгыш ясады. Аның сүзләре буенча, очрашу нәтиҗәле булган: берничә хезмәттәшлек килешүе төзелгән. Тышкы элемтәләр департаменты директоры **А.КРЫЛОВ** КФУ турындагы күргәзмә материаллары белән таныштырды. Аннан соң хуҗалык эшләре буенча проректор **Л.САФИУЛЛИН** җирле үзидарә һәм торак-коммуналь сәясәт буенча РФнең Иҗтимагый палата комиссиясенең тәкъдимнәре турында әйтте.

• • • •

**21-23 ФЕВРАЛЬДӘ** Яр Чаллы институтының гаммәви коммуникацияләр кафедрасы студентлары «Росинка» сәламәтләндерү лагере базасында оештырылган **СТУДАКТИВ ФОРУМЫНЫҢ КЫШКЫ ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАСЫНДА КАТНАШТЫЛАР**. Алар өчен тренинг, мастер-класслар, ачык лекцияләр һәм спорт-сәламәтләндерү чаралары әзерләнгән иде.

• • • •

**24 ФЕВРАЛЬДӘ И.ГАФУРОВ ИНЖЕНЕРИЯ ИНСТИТУТЫ КОЛЛЕКТИВЫ** белән **ОЧРАШТЫ**. Чарада структур бүлекнең 2013 елгы нәтиҗәләре һәм алдагы елга планнары хакында сөйләштеләр. Хисапны институт директоры **Н.КАШАПОВ** тотты. Презентациядән соң фикер алышуда ректор игътибарны күбрәк дисциплинаара элемтәләргә юнәлтергә киңәш итте.

• • • •

**25 ФЕВРАЛЬ** көнне КФУда менеджмент өлкәсендә белем бирү буенча Россия вузлары укыту-методик берләшмәләренең **ИКЕ КӨНЛЕК КҮЧМӘ УТЫРЫШЫ** («Дәүләт һәм муниципаль идарәсе» секциясе) **АЧЫЛДЫ**. Чара Идарә һәм территориаль үсеш институты базасында үтте.

• • • •

**25 ФЕВРАЛЬДӘ УФА**да **«МӘГАРИФ. ФӘН. КАРЬЕРА 2014» КҮРГӘЗМӘСЕ АЧЫЛДЫ**. Анда КФУ үзенең Физика институтын, Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтын, Халыкара бәйләнешләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтларын тәкъдир итте.

• • • •

**В.ПОТАНИН СТИПЕНДИЯСЕ ПРОГРАММАСЫНДА ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕ БИЛГЕЛЕ БУЛДЫ.** Ике тур нәтиҗәләре буенча илебезнең 70 югары уку йортыннан 300 шәкерт сайлап алынган. Алар арасында КФУ магистрантлары да бар: Ф.Әхәтова (Фундаменталь медицина һәм биология институты ), А.Лин (А.М.Бутлеров ис. Химия институты), А.Устимов һәм А.Шакиров (Икътисад һәм финанс институты), Т.Якунина (юридик факультет). Алар магистратурада укып бетергәнчегә кадәр ай саен 15 000 стипендия алачак.

• • • •

ИТИС югары мәктәбе студенты **САБИНА САКАЕВА** Яндекс Tolstoy Startup Campта сайлап алу турын узды һәм **ЯНДЕКСТА СТАЖИРОВКА ҮТҮ МӨМКИНЛЕГЕНӘ ИЯ БУЛДЫ**. Ул 3 марттан алып 25 апрельгә кадәр Мәскәүдә үз проектын эшләү белән шөгыльләнәчәк.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Эшлекле сөйләшү

# Төп игътибар – сыйфатка!

Алинә САДЫЙКОВА

25 февраль көнне ректор И.Гафуров катнашында ИТИС югары мәктәбе коллективының 2013 ел нәтиҗәләренә һәм 2014 елга планнарына багышланган утырыш булды.

Чарада шулай ук икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.Сафиуллин**, уку-укыту эшләре буенча проректор **Р.Минзарипов**, хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры **Р.Латыйпов**, ИТИС югары мәктәбенең укытучылары, галимнәре h.б. катнашты.

Утырыш И.Гафуровның чыгышы белән башланып китте. Ул, катнашучыларны сәламләп, әлеге төр чараларның мөһимлегенә басым ясады: «Куйган максатларга ирешү өчен, дөрес юнәлештә барганлыгыбызга инанырга кирәк. Моның өчен башка уку йортлары, аларның эшчәнлекләре, үзенчәлекләре белән танышып, өйрәнеп, үзебезнең юнәлешне табарга кирәк. Башкаларны кабатласак, ерак китә алмаячакбыз! Без үз юнәлешебне үзебез сайларга тиеш!»



Ректордан соң, сүзне ИТИС югары мәктәбе директоры **Айрат Хасьянов** алды. Ул үзе җитәкли торган структур бүлекчәнең эшчәнлеге, инде эшләнгән һәм алга таба башкарылачак эшләр турында сөйләде. Әлеге югары мәктәп, күптән түгел генә оешкан яңа структура булуга карамастан, үзен яхшы яктан күрсәтергә өлгерде. Аларның университет куйган биеклекләргә ирешүләре – шуның ачык мисалы булып тора. А.Хасьянов ИТИСны гуманитар һәм төгәл-табигый фәннәрнең кисешкән урыны дип билгеләде. Шуңа күрә алар, университетыбызның башка институтлары белән тыгыз элемтәдә торып, уртак эшчәнлек алып баралар.

Югары мәктәп IT өлкәсендәге дөньякүләм танылган күп кенә компанияләр белән дә хезмәттәшлек итә. Шуның нәтиҗәсендә студентларга да әлеге оешмалар базасында көчләрен сынап карарга мөмкинлек булдырылган. Мисал өчен, шәкертләр хәзерге көндә бик популяр булган андроидлар өчен кайбер приложениеләрне үзләре эшләп чыгаралар. Әйтергә кирәк, аларның бу эшләре бик нәтиҗәле һәм уңышлы бара. Шулай да, университет җитәкчелеге фикеренчә, бу процессны тизләтергә һәм күләме ягыннан да арттырырга кирәк.

Белем бирү юнәлешенә килгәндә, бүгенге көндә ИТИСта 370 студент укый. 2014-2015 уку елына бу сан 630га җитәр дип фаразлана. Магистратура буенча ике яңа программа (PM һәм SSME) ачып җибәрү планлаштырыла. Алар инглиз телендә укытуга көйләнгән. Чит телдә укыта башлауның сәбәбе дә бар: чит ил студентларын җәлеп итү, студентлар алмашы программасын гамәлгә ашыра башлау. Хәзерге вакытта ИТИС җитәкчелеге Финляндия университеты белән бу турыда сөйләшүләр алып бара. Узган уку елында «мәктәп»тә яңа 10 өстәмә белем бирү программалары кабул ителде, мәктәп укучылары өчен күп санлы курслар оештырыла.



Фәнни эшчәнлеккә дә зур игътибар бирелә. Һәрдаим масштаблы халыкара конференцияләр, очрашулар, түгәрәк өстәлләр оештырыла, тәҗрибә туплана. Заман таләп иткәнчә, «мәктәп» хезмәткәрләренең исемнәре дөньякүләм басмаларда да күренә.

Бу ирешелгәннәр, әлбәттә, чик түгел. Алга таба «мәктәп» җитәкчелеге студентларның мөстәкыйль эшчәнлеген арттыру өчен электрон курслар, инглиз телендә укытылачак курслар, яңа программалар кертеп җибәрергә, IT өлкәсендә танылган, югары квалификацияле белгечләр чакырырга ниятлиләр. Директор сүзләренчә, нинди генә яңалык кертсәләр дә, төп игътибар сыйфат системасына бирелә һәм биреләчәк тә.

Очрашу азагында ректор фикерләре белән уртаклашты, кайбер кисәтүләрен дә җиткерде. «Мәктәп» коллективының бердәм эшләрен хуплап: «Куйган максатларга ирешү өчен барлык көчләрне бергә тупларга, эшли белгәнебезне күрсәтергә кирәк!» – диде.

• Чара

Булачак журналистларның Россия һәм Татарстан хезмәт базарындагы урыны, аларның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсе хакында Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты һәм «Идел» әдәби-иҗтимагый журналы оештырган брифингта сөйләштеләр.

# Һөнәри мобильлек – төп таләп?

Галия СӘЛИМОВА

Иң элек катнашучылар журналист-белгечнең һөнәри мобильлеге мәсьәләсе турында сүз алып бардылар. Бүгенге чыгарылыш курс студентларының төп сыйфат критерийлары хакында да фикерләр яңгырады. Заман журналист һөнәренә карата югары таләпләр куя. Бүген күпчелек илләрдә бакалавр – гыйльми дәрәҗәнең беренче баскычы. Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында да шушы караш хуплана. Бу хакта Институт директоры Наил Мөхәррәмов җиткерде.

Әңгәмәдә «Татар-информ» агентлыгы генераль директоры Л.Толчинский да катнашты. «Мин, теләсә кайсы җитәкче кебек, квалификацияле хезмәткәрләр туплау яклы. Аның гыйльми дәрәҗәсе бармы-юкмы – анысы мөһим түгел,» – диде ул чыгышында. «Казанские ведомости» газетасының редакторы В.Якупова студентларны эшкә өйрәтүне аларның кечкенә булса да язмаларын матбугатта бастырудан башларга кирәклеге хакында әйтте. TatCenter.ru порталының баш мөхәррире Р.Сиражетдинов исә студентларны үз редакциясенә икътисади һәм эшлекле журналистика серләренә төшенергә чакырды. Әңгәмәгә «Матбугат.ру» порталының алыштыргысыз мөхәррире Д.Сәфәров та кушылды. «Российская газета» корреспонденты Т.Әлимов журналистның универсал булырга тиешлеге хакындагы фикерләре белән уртаклашты. Әңгәмәдә күтәрелгән мәсьәләләргә үз карашларын КФУның татар журналистикасы кафедрасы мөдире В.Гарифуллин һәм КФУның телетапшыру һәм тележитештерү кафедрасы лабораториясе җитәкчесе В.Егоров та җиткерде. 2 курс студенты, kpfu.ru сайтындагы күпчелек фотоларның авторы Руслан Дәүләтшин, үз чиратында, мондый очрашуда катнашуы һәм республика ММЧ мөхәррирләре белән күзгә-күз очрашып сөйләшә алуына шатлануын белдерде.

Әлеге очрашуларның киләчәге якты – монысы шиксез. Аларның ешлыгы артуын һәм ритмик характер алуын гына телисе кала.

• Белем баскычлары

# Апаска «педагоглар десанты» төште

**Әнвәр ХУҖИӘХМӘТОВ,** Укыту һәм тәрбия методологиясе кафедрасы җитәкчесе, профессор

КФУның педагоглар десанты Апас, Каратун, Иске Йомралы, Биеш, Морзалар урта мәктәпләренә «төште». Профориентацион эш төркеме составында КФУның Психология һәм белем бирү институты укытучылары Җ.Г.Нигъмәтов, И.Ф.Яруллин, Г.Ф.Биктаһирова, Л.А.Рыбакова һәм студентлар бар иде.

Бүгенге заманның икътисади һәм сәяси вәзгыяте кешенең шәхси психофизиологик үзенчәлекләренә көннән-көн югарырак таләпләр куярга мәҗбүр итә. Базар мөнәсәбәтләре хезмәтнең рәвешен һәм максатларын тамырдан үзгәртә: аның интенсивлыгы үсә, киеренкелеге арта, югары профессиональлек, чыдамлык һәм җаваплылык таләп ителә. Бу уңайдан мәктәп укучылары һәм яшьләр арасында максатчан рәвештә профориентацион эш алып баруга зур игътибар бирергә кирәк. Әлеге эш шәхеснең һөнәри ниятләрен формалаштыручы һәм тормышка ашыручы төп факторлар системасы турындагы тирән белемгә таянып алып барылырга тиеш. КФУ бу юнәлештә даими эшләп килә. Шушы көннәрдә мондый профориентацион эш Апас районы мәктәпләрендә уздырылды.

Апас районының белем йортларында бу уңайдан методик семинарлар, түгәрәк өстәл һәм әңгәмә-дискуссияләр оештырылды. Балалар КФУ, андагы төп уку юнәлешләре белән якыннанрак таныштылар, консультация алды. Укучылар һәм укытучылар арасында анкеталаштыру уздырылды.

Профессор Җ.Г.Нигъмәтов «Инклюзив белем бирү: асылы, торышы һәм аны ТРда кертү» дигән темага методик семинар үткәрде. Инклюзия – үзенчәлекле белем бирү таләп ителгән балаларга гына түгел, саусәламәт балаларны укыту өчен дә алга киткән, гуманлы, нәтиҗәле белем бирү системасы. Инклюзия һәр кешегә, мәктәп системасы критерийларына туры килү-килмәвенә карамастан, белем алуга хокук бирә. Мәктәп белем бирү функциясен генә үтәп калмыйча, баланың төп тормыш эшчәнлеге өлкәсе дә булып тора. Индивидуальлекне хөрмәтләү һәм кабул итү аша шәхес формалаша. Өстәвенә, мәктәптә укучылар коллективта берберсе белән аралаша, үзара мөнәсәбәткә керә, укытучы белән бергә белем бирү проблемаларын иҗади рәвештә чишәргә өйрәнә.

Өлкән укытучы И.Ф.Яруллин «Белем бирүнең сыйфатын күтәрү» дигән темага доклад ясады. Безгә «Сыйфатлы белем бирү – Россиянең киләчәге» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Ә бәлки, сыйфатлы белем – кешегә ирек вәгъдә итүче төп ресурстыр? Бүген һәм иртәгә генә түгел, ә киләчәктәге ирек, гомуми ирек түгел, ә яңа, әлегә билгесез шартларда ирекле һәм нәтиҗәле эшли алу, ирекле сайлау мөмкинлегедер? Ник дигәндә, ирек төшенчәсенең төп асылы гади: белемең булмаса, син сайлый алмыйсың. Әгәр белемең булса, синең сайлау мөмкинлегең бар, син үзеңне һәм якыннарыңны уңай яшәү шартлары белән тәэмин итә алачаксың.

И.Ф.Яруллин чыгышын КФУның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында төшерелгән «Чорлар борылышында...» видеофильмы белән дәвам итте. Доцентлар Г.Ф.Биктаһирова һәм Л.А.Рыбакова КФУның Психология һәм белем бирү институты, кабул итү кампаниясе турында бәйнә-бәйнә сөйләделәр, һәр юнәлеш буенча аерым консультацияләр уздырдылар. Студентлар тормышы турында исә 3 курс студенты А.Җәләлетдинова сөйләде.

Чыгышлар барышында КФУга укырга керергә теләгән һәркемгә төп киңәш тә яңгырады: инициативалырак һәм оешканрак булыгыз! Университетта укуыгызның уңышлы булуы бары тик сездән генә тора.

Укырга керүчеләр өчен тагын бер яңалык бар: абитуриентлар өчен махсус портал булдырылган. Аңа кереп, булачак студентлар документларын биргән институтлардагы конкурсны күзәтә ала. Документларны һәм традицион, һәм электрон рәвештә бирергә мөмкин.

Һәр чыгыш дискуссияләргә бай булды, укытучылар да, укучылар да биргән сорауларына тулы һәм эчтәлекле җаваплар алдылар. Ахырда югары сыйныф укучылары арасында үткәрелгән сораштыру нәтиҗәләре буенча аларның күбесенең киләчәктә КФУга укырга керү теләге бар икәнлеге билгеле булды.



**Гасыр божралары**

# Ак канатлы профессор

Әбүбәкер Батыргәрәй улы Терегулов – терапевт, медицина фәннәре докторы (1927), профессор (1929), ТАССРның һәм РСФСРның атказанган фән эшлеклесе (1940). Фәнни хезмәтләре Чейн-Стокча сулыш алуга һәм ашкайнату органнарының клиник физиологиясе һәм патологиясенә карый.



*«Ак чәчәкләр» әсәренең үзәгендә – күпне күргән, күпне башыннан кичергән атаклы профессор Әбүзәр Таһиров. Ул Тукай, Ямашевларны күргән, халык арасында яшәп, гади врачтан атаклы профессор дәрәҗәсенә үскән. Әбүзәр абзыйның тормышы һәм эше әсәрдә киң итеп бирелә. Аның өчен халыкка намус белән хезмәт итүдән дә изгерәк бурыч юк. Әбүзәр абзый - гаиләдә дә, эштә дә олы җанлы, миһербанлы, рухи яктан матур кеше..*

Әбүбәкер Терегулов 1885 елның 14 мартында Уфа мөселман руханилары җыенының бүлек җитәкчесе Гәрәй Бәдамша улы Терегулов гаиләсендә дөньяга килә. Яшүсмер Әбүбәкер 1898 елдан Уфа гимназиясендә укый башлый. 1902 елда, әтисе вафат булгач, гаиләнең яшәү шартлары кыенлаша, малайга бу авырлыкны да үз җилкәсенә алырга, өйләргә йөреп, аерым кешеләрнең балаларына дәресләр биреп, акча табарга, шул шартларда укуын да дәвам итәргә туры килә.

Гимназиядә укуын тәмамлаган Әбүбәкер 1906 елда Казан университетының табигать фәннәре факультетына укырга керә. Бер елдан ул медицина юнәлешен сайлый, шунда күчә. Соңрак үзе сөйләвенчә, В.Б.Вересаевның «Записки врача» исемле китабын укыгач, аңарда тормышын медицина өлкәсенә багышлау теләге туа, шуннан соңгы гомере аның дөрес юнәлеш, һөнәр сайлый белүенә даими дәлил була. Ул, өлкән яшенә җиткәч тә, «Яшьлегендә үз мөмкинлеген сизгән, мөмкинлегеннән чыгып һөнәр сайлый белгән кеше, картлыгында уйланып, узган юлына карап, җәмгыятькә бирергә өлгергән хезмәт җимешләрен күреп, күңелендә канәгатьлек сизү бәхетенә ирешә ала», дигән фикердә була.

Уку-белем алу барышында ук Ә.Г.Терегуловта кешенең эчке әгъзаларындагы чирләрне тикшерүгә аеруча омтылыш һәм сәләт булуы ачыклана. Ул III курс студенты чагында ук җәйге каникул көннәрен Минзәлә өязенең Акташ авылында торып бик җаваплы эштә – кинәт таралып киткән холера (эчәк авыруы) чиренә каршы көрәштә уздыра. Шул көннәрдә кеше гомерен саклап калу өчен күпме тырышлык, белем кирәген, дәвалаучының дәваланучы каршында никадәр җаваплы булуын ул беренче кабат чын-чынлап аңлый – бу 1909 ел була.

1911 елда Ә.Г.Терегулов Казан университетының медицина факультетын «Аеруча оста дәвалаучы» дигән дәрәҗәле исемгә лаек булып тәмамлый. Профессор А.Н.Казимбәк аңа зур өметләр баглый, үзе җитәкләгән клиникада калырга, ординаторлык хезмәте башкарырга тәкъдим ясый. Медицина аспирантурасының бер төре булган җитди бу хезмәткә Ә.Г.Терегулов, әлбәттә, хөрмәт белән карый, тик ул моңарчы алган белемен тәҗрибә белән ныгытудан, киләчәккә таба юлын халык арасында эшләүдән башларга уйлый.

1911 елдан ул Уфа губернасының Чишмә станциясе табибы хезмәтен башкара. Ике елдан соң Казан университетына кайта, ординатура тәмамлый, 7 елдан факультетның терапия клиникасы ассистенты була, бу эшендә өлкән ассистент дәрәҗәсенә күтәрелә.

Гражданнар сугышы чорында һәм аннан соң (1918-1921 елларда) дәүләт юлламасы белән башта Томск, аннан Омск университетларында эшли. Эчке авырулар буенча диагностика кафедраларына укытучылар туплауны оештыра. Хезмәтләре аша анда бик уңышлы киләчәге күренсә дә, аның күңелен яшьлек каласы, инде Совет Татарстанының мәркәзе саналган Казан ныграк тарта. Ә.Г.Терегулов тиздән Казан университетының медицина факультетында эшли башлый. 1929 елда университетта җаваплы эшкә – эчке әгъзалар чирләрен тикшерүче кафедрага җитәкче итеп билгеләнә. 1931-1936 елларда Казан медицина институтының уку-укыту эшләре буенча проректоры була.

Бөек Ватан сугышы елларында Ә.Г.Терегулов уку-укыту, дәвалау барышын сүлпәнләндермәү максаты белән яши һәм эшли, әлеге юлда бар көчен һәм сәләтен җигә. Сугыш елларында дөньяга чыгудан туктаган «Казанский медицинский журнал»ның 1957 елда яңадан тууы да Ә.Г.Терегуловның зур тырышлыгына бәйле. Ул барлык Идел буе халыклары өчен аеруча мөһим булган шушы журналның редакторы (1959 елга кадәр), аннан соң редколлегия әгъзасы булып тора.

Ә.Г.Терегуловның тәүге фәнни ачышлары ашказаны халәтен, аның баш мие белән бәйләнешен, бөер эшчәнлеген, шулар бәйләнешендәге табигый булмаган тайпылышлар һәм йөрәк мәсьәләләрен яктырта. Соңгы еллардагы дәвамлы тикшеренүләре кешелеккә бәла булып киң тарала башлаган атеросклероз чирен тикшерү, бу чиргә каршы көрәшкә юнәлтелә.

Галим ТАССР табигатендәге кешегә шифалы байлыклар мәсьәләсе белән дә даими кызыксынып яши, тикшеренүләр ясый. Бүген без бик теләп тормышыбызда файдалана торган Иж суының халыкка танылуында да аның һәм аның җитәкчелегендә эшләгән хезмәттәшләренең җитди өлеше бар.

Казан терапия мәктәбенең үсеше, мәктәпнең нигез ташларын салучы профессорлар Н.А.Виноградов, А.Н.Казимбәк, С.С.Зимницкий, Н.К.Горяев, М.Н.Чебоксаров кебек шәхесләр турында язуы белән дә галим чиксез хөрмәткә лаек.

Әбүбәкер Терегулов 1966 елда 81 яшендә бу фани дөньяны,ихластанбирелгән эшләрен калдырып, арабыздан китә. Аның якты образы матур әдәбиятта да чагылыш тапты. Ул Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романында табиб Әбүзәрнең прототибы итеп алынган.

*Мәгълүмат «Татар галимнәре» китабыннан алынды*

***P.S.** Укучыларбыз, сезнең игътибарга яңа сәхифә тәкъдим итәбез. Ул уку йортыбызның зур юбилеена – 210 еллыгына багышлана. Сездән кызыклы язмалар, иҗат җимешләре көтеп калабыз. Уку йортыбызга бәйле хатирәләрегез белән рәхәтләнеп уртаклаша аласыз.*

**Тәүге адымнар**

# «Исәнмесез, укытучы апа!»

Филология һәм мәдәниятара
багланышлар институтының
**10.02 – 003 төркем студентлары**

Шау-шу, тирә-як кырмыска оясы кебек гөҗ килә. Берәү килә, берәү китә, әмма кеше бер дә кимеми. Алма төшәрлек тә урын юк. Ишек ябылырга да өлгерми, икенче бер нәни куллар аны каерып ачып, ныклы адымнар белән эчкә уза.



Кая килеп эләктек соң без? Өнме бу, әллә төшме? Янәшәдәге төркемдәш кызларга дәшәм: чеметегез әле мине, уянып китмәмме икән? Юк, бу төш түгел һәм без килеп эләккән шау-шулы дөнья ул мәктәп икән. Әйе, гап-гади, балачакта без дә укып үскән, белем алган мәктәп. Әмма нигәдер бүген куркыта, каушата. Без бит инде мәктәпкә гади укучылар булып кына түгел, ә укытучы сыйфатында килдек. Кулда дипломнарыбыз булмаса да, укытучы башкара торган иң зур хезмәтне – балалар белән эшләү, дәрес бирүне без дә өйрәнәчәкбез.

Мәктәп белән танышу көнебез бик кызык үтте. Мәктәп коллективы, хезмәткәрләр безне җылы каршы алдылар, сорауларыбызны тыңлап, киңәшләрен бирделәр. Ә балаларның мөнәсәбәте – үзе бер тарих! Алар безне, без аларны белмибез. Алар да үзләренчә безне күзәтә, без дә, шаккатып, менә нинди икән ул замана баласы, дип карап торабыз. Кайберләре исәнләшеп уза, икенче берәүләре безгә карап, авызын ерып китә.

Мәктәп – бик серле, кызыклы, бала чакка кире алып кайта торган ил. Әлеге практика вакытында студент-практикант бик күп нәрсәгә өйрәнә. Бер үк вакытта житди дә, шаян да була белү сорала. Үзпредметыңны әйбәт белергә тиешсең, чөнки укучылар теләсә кайсы сорауны бирергә мөмкин. Җавап бирә алмасаң, үзең үк уңайсыз хәлдә каласың. Шуңа күрә укытучы һөнәре бик катлаулы, нәзберек һөнәрләрнең берсе. Укытучыбыз Фәрит абый Яхинның «укытучы булган кеше барлык башка өлкәләрдә дә эшли ала» дигән сүзе бар. Мәктәпкә килгәч, бу сүзгә тагын бер кат инандык. Балалар белән уртак тел табу үзе генә дә ни тора! Шулай да безнең сынатырга исәп юк! Дәресләргә яхшы итеп әзерләнеп киләбез, укучылар да тырышлыгыбызны күрәләр, дәресләрегез күңелле дип, гел мактап торалар. Балаларны алдап булмый шул, алар кемнең кем икәнен бик тиз аера.

Мәктәптән кайтып, төркемдәшләр белән тулай торакта күрешү үзе бер түгәрәк өстәлгә әйләнә. Һәр кайсыбыз башыннан кичкәннәре, өч атналык кына булса да тәҗрибәсе белән уртаклаша, кемдер киңәш сорый, икенче берәүләр аңа ярдәмгә ашыга.

Практика чоры – студент өчен икенче тормыш башлану вакыты. Кәгазь өемнәреннән өстәл сыгылып тора, көн дә компьютерың белән бергә йокларга ятасың, аның белән уянасың... Интернет челтәрендәге социаль төркемнәр мәктәп тормышын чагылдырган фикерләр, сүзләр белән тулды. Дуслар артты, алар – үзебез җитәкләгән сыйныф укучылары. Инде син, мәктәпкә килеп, тиз генә чишенү бүлмәсенә узам димә, ишектән керүгә, сине шау-шу белән бергә, «Исәнмесез, укытучы апа!» дигән якын да, ягымлы да тавышлар каршы ала...

**Туган тел сагында**

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар» исемле гомуми урта, махсус урта һәм югары белем бирү йортларында укучыларның V Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе узды.

# Тел белгән һәркайда кирәк!

Ачылыш тантанасында институт директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов билгеләп үткәнчә, чараның Халыкара туган тел көнендә оештырылуы – үзе бер тантана. «Бүген бар халыклар да үз ана телләренең мөһимлеген, әһәмиятен аңлаган, аны саклаган халәттә генә безнең аралашу коралыбыз үсә, камилләшә алачак. Сез, яшь буын, иң беренче чиратта, шуңа төшенергә тиешсез. Ана телебезне тирәнтен өйрәнеп, без башка телләрне дә үзләштерә алачакбыз. Күп тел белгәннәр һәр тармакта һәрвакыт кирәк», – дип мөрәҗәгать итте укучыларга директор. Пленар утырыш ахырында өлкән сыйныф укучыларының «Татарларга тылмачлар кирәк» конкурсында һәм югары уку йортларында белем алучы рус телләләр өчен татар теленнән олимпиадада җиңүчеләргә, җитәкчеләренә истәлекле бүләкләр, дипломнар тапшырылды.

Иң яхшы чыгыш буларак сайлап алынган докладлар нигезендә конференция материаллары җыентык итеп нәшер ителәчәк. Конференция эшендә катнашкан төрле районнардан килгән укытучылар фикеренчә, лингвокультурология чагыштырмача яңа фәнни юнәлешләрнең берсе булса да, укучылар аның белән тирән кызыксыналар һәм алар тарафыннан кызыклы хезмәтләр языла. Фәннең әлеге юнәлешенә нигез салган галимнәр, бу эшнең башында торган Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты мондый чараны алга таба да оештырсын иде, дигән теләкләрен дә җиткерде мөгаллимнәр.

• Мәдәният һәм сәнгать елы

# «Буш вакытта да рәсем ясыйм»

**Илмира АХУНОВА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр
институты

Сәнгатьнең бүген нинди генә төрләре юк. Әле берничә ел элек кенә урамдагы стеналарга ясалган рәсемнәргә гаҗәпләнеп карый идек. Имеш, кемнеңдер эше беткән дә, стена пычратып йөри. Баксаң, бу заманча сәнгать төре икән, фәнни телдә үз исеме дә бар. Граффити – стеналарга яки башка төрле өслекләргә буяу яисә кара белән ясалган рәсемнәр. Заманча сәнгатьне безнең илдә әле соңгы ун елда гына үзләштерә башладылар, шуңа күрә дә халык өчен аны кабул итү авыррак. Аеруча өлкән буынга. Яңа танышым Рөстәм фикеренчә, безнең халыкка да ияләшергә вакыт, сәнгатьнең бөтен төрен дә аңлый белергә кирәк, һәрнәрсәнең үз урыны бар. Башкалабызда танылып өлгергән граффити мастер, дизайнер Рөстәм Сәлимгәрәев белән әнә шул хакта сөйләшеп алдык.

**– Рөстәм, рәсем сәнгатенә беренче адымнарың кайчан башланды?**

- Мин тумышым белән Түбән Кама районы, Кама Аланы бистәсеннән. Күп яшьтәшләрем кебек, рәсемнәр ясау белән мавыктым. Бу сәләтемне күреп алган әти-әнием бистәдә әле генә ачылган сәнгать мәктәбенә бирергә булганнар. Алга таба, унберенче сыйныфны тәмамлап, имтиханнарны тапшыргач, Казан сәнгать училищесының дизайнерлар әзерләү бүлегенә укырга кердем. Беренче елларны училищеда укуы кыен булды. Казан минем өчен чит шәһәр иде, аннары училищеда да беренче курста бик авыр булды. Бистәдә алган белемнәр генә җитмәде, үземә бик тырышырга туры килде. Училищены тәмамлаганнан соң, ТДГПУның дизайн бүлегенә укырга кердем. Һәм тормышымны тулысынча рәсем белән бәйләдем, дисәң дә була.

**- Гаиләгездә рәссамнар бармы?**

- Әти-әнинем сәнгать кешеләре түгел. Әти төзелештә эшли, әни бухгалтер. Шулай да әтинең дуслары, туганнар сөйләве буенча, аның кечкенә чакта рәсемнәр ясавы турында беләм. Мин кечкенә чакта әнинең журнал бите кырыйларына фигуралы шуучыларны ясавын хәтерлим. Без гаиләдә ике бала. Абыем да, минем кебек, балачакта рәсемнәр ясый иде. Тик ул бөтенләй башка юнәлеш буенча китте, ә мин сәнгатьне сайладым.



**- Ә ни өчен син нәкъ менә граффитины сайладың?**

**- Мин яшүсмер вак**ытымнан ук заманча музыка – хип-хоп белән кызыксына идем. Нишләптер, шундый гадәти булмаган, заманчалаштырылган сәнгать төрләре мине үзенә җәлеп итә. Университетта укыган вакытта, граффити белән мавыгучы яшьтәшләремне очраттым һәм, үзем дә сизмәстән, аларның дулкынына кушылып киттем. Яңа дусларым белән, җай чыккан саен, коймаларга төрле темага караган рәсемнәр ясый башладым. Иҗат җимешләрем турында уңай фикерләр генә ишеткәч, баш-аягым белән сәнгатьнең бу төренә чумдым.

**- Үз белгечлегең буенча, дизайнер булып, берәр оешмада эшлисең килмиме?**

- Башта, дизайнер белгечлеге буенча диплом алгач, берәр җитди оешманың офисында тыныч кына дизайнер булып эшләрмен дип уйлаган идем. Хәзерге вакытта үземнең нинди дер оешмада эшләвемне күз алдыма да китермим. Мин иҗат ирегенә ияләштем, үземә ошаган эш белән шөгыльләнәм. Офис тамоны яса, тегене эшлә дип утырганнарына түзә алмас идем. Аннары, кемдер кушуы буенча ясалган рәсемнәр чын күңелдән булмый да.


**- Бүген инде сезнең үз остаханәгез дә бар. Иҗатыгыз гөрли, тик әле бит син мәктәптә дә эшләргә өлгерәсең?**

- Әйе, берничә ел элек үзем кебек яшь рәссамнар белән аерым бер бинада остаханәбезне булдырдык. Эш бүлмәбездә чын иҗат атмосферасы хөкем сөрә. Күбрәк граффити белән мавыксам да, остаханәдә булганда, кәгазьгә рәсемнәр, киндер тукымага картиналар ясыйм. Атнага өч тапкыр Казандагы бер мәктәптә рәсем түгәрәге алып барам. Аларга сәнгать мәктәбендә алган белемнәремне бирергә тырышам, башта алар рәсем ясауның нигезен аңларга тиеш.

**- Күбрәк нинди темаларга ясарга яратасың?**

- Рәсемнәр тематикасы һәрвакыт үзгәреп тора. Ул иҗади күтәренкелек белән дә бәйле. Нинди дә булса яңа әйбер күреп, илһамланып, шул темага рәсем ясый башларга да мөмкинмен. Шуңа күрә теге яки бу әйберне күбрәк ясарга яратам дип әйтә алмыйм. Шулай да күбрәк кешеләр һәм хайваннарны ясарга яратам, табигать күренешләренә өстенлек бирмим. Минем картиналар заманча сулыш белән ясалган. Аларның һәммәсенә нинди дер серле мәгънә салынган. Кайбер рәсемнәремнең тулы мәгънәсен үземә дә аңлавы авыр.







**- Дусларыңа, туганнарыңа үзең ясаган картиналарны бүләк иткәнең бармы?**

- Үзем ясаган рәсемнәрне бүләк итәргә яратмыйм. Рәсемне яхшы ясаганны алар белә. Һәм миңа шундый җиңел генә бирелгән эшне аларга бүләк итсәм, үземә читен булачак. Инде рәсем ясау белән мавыкмаган кеше бүләк итсә, шатландырыр иде. Шулай да, үземне профессиональ рәссам дип санамыйм.

**- Рәсем ясаудан башка тагын берәр шөгылең бармы?**

- Дөресен әйтергә кирәк, юк. Буш вакытымда да рәсем ясауның бүтән төрләре белән кызыксынам. Эшне җиренә җиткерүне хуп күрәм. Бер үк вакытта рәсем ясаучы да, җырлаучы да, шигырь язучы да булган кешеләрне аңламыйм, эшнең сыйфаты шуның кадәр генә була, дип уйлыйм.

**- Иҗатың белән таныштырганың өчен рәхмәт. Уңышлар сиңа, Рөстәм.**

• Сәламәтлек

# Без салкыннан курыкмыйбыз!

**Лиана МӘРДӘНОВА,** Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Кыз кеше булсам да, бу елгы Ватанны саклаучылар көнен бәйрәм итеп үткәрдем. Атна буе «атна азагын» көтеп йөрдек Илүзә белән. «Сәламәтлек поезды»на утырып, чаңгы шуарга барабыз, янәсе. 23е килеп тә җитте. Иртәнге алтыда торып, киенеп-ясанып, Тимер юл вокзалына юл алдык…

Тулай тороктан чыктык та шок хәлендә басып торабыз. Тышка Суык бабай янә килгән, салкын үзәккә үтмәле икән. Суык безгә «непачум» дип, киттек тагын үзе.

Вокзалда инде шактый гына студентлар җыелган иде. Нәрсә соң ул «Сәламәтлек поезды» диярсез? Ул – сәламәт яшәү рәвешен студентларга «йоктыру». Әлеге проект инде 4 ел рәттән уңышлы гына эшләп килә икән. Һәр елны институтлар чаңгы, чана шуарга, күңел ачып кайтырга бара. Бар кешеләрне кызыктырып, күңелле ялга «Маяк» чаңгы шуу йортына киттек.

Баксаң, бирелдә олимпиада чемпионнары әзерләнә икән. Тренировкага килгән егет-кызларның киләчәктә Россия, Татарстан данын яклаучылар рәтендә булачагына ышанам.

Башкаларга чаңгы, тюбинглар таратканда, Илүзә белән мин табигать карап йөргәнбез. Безгә «ватык карета» калган. Аны алып тауга киттек. Беренче булып чыршылар арасына Илүзә төшеп китте. Кычкыруын ишетсәгез!!! «Валлаһи, бер-бер хәл булгандыр инде», – дисәм, май кояшы кебек балкып, йөгерә-йөгерә менеп ята бу. Шулай бар дөньяны гөрләтеп тау шудык та, аяк бармакларын сизми башлагач, талон артыннан киттек.

Иртән «Соңга калабыз бит инде, тизрәк бул!» – дип Илүзә ашыктырып



торганда каушап эчелгән чәй инде күптән онытылган иде. Эчемдәге бүреләр ашау сүзен ишеткәч, җанланып киттеләр. Татар гамбургеры (булочка арасында калын гына кәтлит), өчпочмак, салат, шоколад белән рәхәтләнеп чәй эчтек. Яшиселәр килеп китте, тәнгә җылы, җанга рәхәтлек йөгерде.

Аннан соң «Буран»да йөрдек. Тирә-ягымдагы нарат-чыршылар белән хозурланып барганда, шофер абый: «Хочешь порулить?» – димәсенме? Менә бу сүзләрдән соң, 23 февральнең нәкъ минем бәйрәм икәнен аңладым. Аллага шөкер, Яшел Үзәннең бер агачын да, кешеләрен дә бәрдермәдем.

Ә аннан соң биедек, футбол уйнадык, җырладык. Кайтып киттек...

Мондый 23 февраль өчен КФУга зур рәхмәт! Мондый проектлар елга бер түгел, хәтта атнага ике булса да комачауламас иде.





DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.